ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2024 Балык Бистәсе штп. №306пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә, баш бухгалтерларына, бухгалтерларына һәм белгечләренә (муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 27.05.2019 ел, №181пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының "Шәһәр һәм авыл җирлекләренең үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә, бухгалтерларына һәм белгечләренә 2025 елның 1 гыйнварыннан билгеләнә торган хезмәт өчен түләү турында" 07.10.2024 ел, №03-12/7086 хаты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә, баш бухгалтерларына, бухгалтерларына һәм белгечләренә (муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 27.05.2019 ел, №181пи карарына ( 20.04.2023 №124пи; от 18.09.2023 №318пи редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмә» кушымтасының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм | Вазифаи оклад, сум |
|---|---|

| белгечләр вазыйфалары | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 33 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 31 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 31 500 |
| Начальник отдела | 27 700 | 27 700 |
| Әйдәүче бухгалтер | 25 300 | 25 300 |
| Бухгалтер | 24 000 | 24 000 |

Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып структурада һәркайсында 5 берәмлектән дә ким булмаган кимендә 3 бүлек булуы тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.»;

1.2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмә» кушымтасының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр | 3,5 мең кешедән артык |
| Баш бухгалтер | 25 700 сум | 27 000 сум |
| Бухгалтер | - | 24 500 сум |

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының штат расписаниесенә бухгалтер вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык кеше булу тора.»;

1.3 4 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) ай саен акчалата бүләкләү, вазыйфаи окладларның 15 проценты күләмендә"»

2.Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме һәм шул ук квалификациядәге эшләр башкарылуы сакланып калганда, хезмәткәрләрнең хезмәт хакының әлеге карар нигезендә билгеләнә торган күләме 2024 елның 31 декабренә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе И.М. Ногмановага йөкләргә (килешү буенча).

Җитәкче Д. А. Сатдинов